СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**22.05.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 188**

2017 елның беренче кварталы өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында

«Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның 2017 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматын тыңлаганнан соң һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2017 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

| | | |
|---|---|---|
| | | Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 22 маендагы 188 номерлы карарына кушымта |
| | | |
| ***2017 елның 1 апреленә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды ассигнованиеләреннән файдалану турында мәгълүмат*** | | |
| | | |
| ***№ п/п*** | ***Түләүне билгеләү*** | ***Сумма (сум)*** |
| 1 | Дәвалауга матди ярдәм күрсәтү, башка матди ярдәм күрсәтү | 70 000,00 |
| 2 | Мактаулы гражданнарның вафатына бәйле рәвештә матди ярдәм күрсәтү | 25 000,00 |
| 3 | Күчемсез милек объектының базар бәясен бәяләү һәм җир кишәрлекләрен ызанлау | 25 000,00 |
| 4 | Административ комиссия эшчәнлеге белән бәйле почта чыгымнарын түләү өчен | 50 000,00 |
| 5 | 2017 елда Крещение бәйрәмен үткәрү көннәрендә юлларны һәм стоянкаларны механикалаштырып җыештыруга финанс ярдәме күрсәтү | 40 000,00 |
| 6 | "Коммуналь хуҗалык" МУП Зеленодольск шәһәренең юл - урам челтәрен кардан чистартуга киткән чыгымнарны компенсацияләү өчен (билгеләнгән урыннарда кар чыгару һәм җыюны да кертеп) | 2 299 997,14 |
| 7 | 2017 елның 1 апрелендә Ситтард шәһәренә (Нидерланд) Сетокан буенча Европа Кубогына Гайнетдинов Марсель Илсур улын сәфәр белән командировкага җибәрү | 50 000,00 |
| 8 | ТР ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасына юбилей чараларын үткәрү өчен "Зеленодольск муниципаль районы ветераннар Советы"на ярдәм күрсәтү | 133 030,00 |
| 9 | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренә матди ярдәм күрсәтү | 50 000,00 |
| | | **2 743 027,14** |